# КАРАР

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Звезда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Хорновар-Шигали авылында гражданнар җыены**

**02 нче декабрь 2021 ел** **Хорновар-Шигали авылы** **№1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Звезда авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең Хорновар-Шигали торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2021 елның 02 декабре**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Советының 11.10.2019 ел, № 53/1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда, гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, 2021 елның 02 декабрендә төзелгән Хисап комиссиясенең, 2021 елның 02 декабрендә узган халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 97 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-**51**, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның **52,58** % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан **51** кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның **100%** ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы **0** кеше тавыш бирде, бу **0%** тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2021 елның 02 декабрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Звезда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Хорновар-Шигали авылында 2021 елның 02 декабрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләрен-дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Хорновар-Шигали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Горький урамы буенча урнашкан Хорновар-Шигали авылына вак таш җәю;

- Хорновар-Шигали авылында урам утларын ремонтлау” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2022 елда Чүпрәле муниципаль районының Хорновар-Шигали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Горький урамы буенча урнашкан Хорновар-Шигали авылына вак таш җәю;

- Хорновар-Шигали авылында урам утларын ремонтлау.

4. Әлеге карарны Хорновар-Шигали авылы, Центральная урамы, 5 нче йорт, Звезда авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Звезда Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы,
рәислек итүче
гранданнар җыенында М.В.Денисова